МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА,
АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-
КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА
ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 115/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

« 20 » 09 2022

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм агынты суны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын билгеләү һәм ачыклау кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь хезмәтләр күрсәтү һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 3 февралендәге 92 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм агынты суны агызу буенча коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгына (20.05.2013 №62/о, 05.05.2017 №95/о, 10.09.2019 №119/о, 24.03.2020 №51/о, 22.07.2022 №76/о боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән)

үзгәреш кертеп, 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында агынты торган суларны агызу нормативы күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында салкын һәм кайнар су коммуналь ресурсларын куллану нормативларыннан чыгып билгеләнә.».

2. Юридик бүлеккә (Э.Ю.Латыйповага), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) бу боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан ун эш көне эчендә аның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.М. Фроловка йөкләргә.

Министр М.М.Айзатуллин

Отдел контроля исполнения документов